КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«5» апрель 2018 ел. № 8-п

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы тору турында законнар үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре турында аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 11 декабрендәге 1092 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Агентлыкның 2016 елның 1 июлендәге 21-п номерлы боерыгы белән расланган “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлекле 3.4.3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

“3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, “д” пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан соратып алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, “д” пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән чыгарылмалар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктларында бәян ителгән карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр”.

2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны җитәкченең беренче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын
вакытлыча башкаручы Э.Ф. Әхмәтова